ГНБУ «АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
ИНСТИТУТ ТАТАРСКОЙ ЭНЦИКЛОПЕДИИ
И РЕГИОНОВЕДЕНИЯ ИМ. М. ХАСАНОВА
АКАДЕМИИ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ РЕГИОНОВЕДЕНИЯ И НАУКОВЕДЕНИЯ

Сборник материалов
XV Республиканской научно-практической конференции

г. Казань, 18 марта 2026 г.

Казань — 2026

УДК 001.18; 908
ББК 72.5; 66.3
А43

Рекомендовано к изданию
Ученым советом Института татарской энциклопедии
и регионоведения им. М. Хасанова Академии наук
Республики Татарстан, протокол №2 от 28.04.2026

Редакционная коллегия:
канд. иск. **Э.М. Галимова**;
д-р ист. наук, проф. **Р.В. Шайдуллин**;
канд. ист. наук, доц. **Л.М. Айнутдинова;**
канд. ист. наук **Б.Л. Хамидуллин;**
канд. пед. наук **Э.М. Гилязиева**

А43 Актуальные проблемы регионоведения и науковедения: сборник материалов XV Республиканской научно-практической конференции (г. Казань, 18 марта 2026 г.) / Институт татарской энциклопедии и регионоведения им. М. Хасанова АН РТ. — Казань: Изд-во АН РТ, 2026. — 244 с.

В сборнике представлены статьи участников XV Республиканской научно-практической конференции «Актуальные проблемы регионоведения и науковедения», посвященной результатам социокультурных и народоведческих исследований в России и Татарстане, а также вопросам общественно-политического и экономического развития регионов, изучению татарской диаспоры в России и за рубежом.

Издание адресовано историкам, краеведам, молодым ученым и специалистам в сфере истории, народоведения, энциклопедистики и истории науки.

ISBN 978-5-9690-1456-5

© Коллектив авторов, 2026
© Институт татарской энциклопедии
и регионоведения АН РТ, 2026

5. Татары в истории Киргизии. Прошлое и современность: Материалы Международной научно-практической конференции (г. Бишкек, 6 июня 2009 г.). Бишкек: Изд-во КРСУ, 2010. 160 с.

УДК 030:930.85(=512.145) + 94(470.41)»636/1237″

ТАТАР ХАЛКЫ ТАРИХЫНЫҢ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕНЕҢ МӨҺИМ ЭТАПЛАРЫ БУЕНЧА ЭНЦИКЛОПЕДИЯЛӘР ӘЗЕРЛӘҮ КИРӘКЛЕГЕ ТУРЫНДА

О НЕОБХОДИМОСТИ ПОДГОТОВКИ ЭНЦИКЛОПЕДИЙ ПО ВАЖНЕЙШИМ ЭТАПАМ ИСТОРИИ И КУЛЬТУРЫ ТАТАРСКОГО НАРОДА

ON THE NEED TO PREPARE ENCYCLOPEDIAS ON THE MOST IMPORTANT STAGES OF HISTORY AND CULTURE OF THE TATAR PEOPLE

Б.Л. Хамидуллин,
Институт татарской энциклопедии и регионоведения им. М. Хасанова Академии наук Республики Татарстан, г. Казань
B.L. Khamidullin,
Institute of the Tatar Encyclopedia and Regional Studies named after M. Khasanov of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan

Аннотация. Содержание статьи представляет краткое изложение предыстории, истории и культуры Волжской Булгарии и Золотой Орды, эволюции этнополитонима «татары», рассмотрение древних и средневековых этапов этногенеза и культурогенеза современной татарской нации и политогенеза Республики Татарстан. В публикации обосновывается важность популяризации научных знаний о средневековых государствах Центральной Евразии — Волжской Булгарии и Золотой Орде — и их богатом этнополитическом, материальном и духовном наследии.

Кроме того, в статье обозначены предварительные результаты работы автора и его коллег над словниками энциклопедий «Волжская Булгария» и «Золотая Орда».

Ключевые слова: Волжская Булгария, Золотая Орда, татарские ханства, энциклопедия, энциклопедический словник, энциклопедический словарь, Институт Татарской энциклопедии и регионоведения.

Abstract. The content of the article is a summary of the prehistory, history and culture of Volga Bulgaria and the Golden Horde, the evolution of the ethnopolitonym «Tatars», the consideration of ancient and medieval stages of ethnogenesis and cultural genesis of the modern Tatar nation and the politogenesis of the Republic of Tatarstan. The publication substantiates the importance of popularizing scientific knowledge about the medieval states of Central Eurasia — Volga Bulgaria and the Golden Horde — and their rich ethnopolitical, material and spiritual heritage. In addition, the article outlines the preliminary results of the work of the author and his colleagues on the dictionaries of the encyclopedias «Volga Bulgaria» and «Golden Horde».

Keywords: Volga Bulgaria, Golden Horde, Tatar khanates, encyclopedia, encyclopedic dictionary, Institute of Tatar Encyclopedia and Regional Studies.

Татарстан Республикасы — Россия Федерациясенең тотрыклы үсеш кичерүче субъектларының берсе, гаять куәтле социаль-икътисади, мәдәни, фәнни-белем бирү потенциалына ия төбәк. Республика халыкара мөнәсәбәтләрдә актив катнаша, анда абруйлы чит ил оешмалары белән берлектә зур һәм мәртәбәле икътисади, мәдәни, фәнни чаралар һәм спорт ярышлары уздырыла.

Хәзерге Татарстан территориясендәге дәүләтчелек тарихының тамырлары тирәннән килеп, урта гасырлардагы дәүләтләргә — Һуннар империясенә, Көнбатыш Төрки каһанлыкка һәм Хәзәр каһанлыгына барып тоташа [1; 2]. II–VII гасырларда, тарихта «Халыкларның бөек күчеше» буларак мәгълүм чорда, Ур-

та Идел буйларына актив рәвештә төрки һәм угор кабиләләре үтеп керә. Төбәктә VI–VIII гасырларда шактый ук ишәйгән төрки телле халыкның мәдәнияте асылы-эчтәлеге җәһәтендә Көнбатыш Төрки һәм Хәзәр каһанлыклары, Кара диңгез буендагы Бөек Болгар мәдәниятләренә якын була. VII гасырның 70 нче еллары соңгысы хәзәрләр тарафыннан яулана, нәтиҗәдә, Бөек Болгарның дәүләт хасил иткән халкы булган болгарларның бер өлеше VII–IX гасырларда Каспий буйларының көнбатыш тарафындагы, Төньяк Кавказдагы һәм Кара диңгез буйларының төньягындагы җирләрдән Урта Идел буйларына, Идел-Чулман төбәгенә һәм Урал буеның көнбатышына күчеп китә.

X гасырда болгарлар хәзерге Татарстан Республикасы территориясендә, атаклы Балтыйк-Идел сәүдә юлының нәкъ үзәгендә, Урта Идел һәм Урал буйларында беренче дәүләт — Идел-Чулман Болгарстанын төзиләр [3; 4], аның составына күп кенә җирле төрки һәм кайбер угор-фин кабиләләре, шулай ук фарсы һәм балт-славян кавемнәре вәкилләре керә [5; 6].

Археология истәлекләренең урнашу географиясе гомуми яссылыкта Идел Болгарстанының территориясен күзаллау мөмкинлеге бирә: болгар дәверенең төп ядкәрләре хәзерге Татарстан Республикасы, Чуваш Республикасы, Башкортстан Республикасы, Ульяновск, Самара һәм Пенза өлкәләре территориясендә сакланган. XII гасыр ахырына болгар идарәчеләре үзләренең йогынты өлкәләрен Чулманның югары агымы (хәзерге Пермь крае) һәм Иделнең үзәге Саксин шәһәрендә урнашкан түбәнге агымы (хәзерге Әстерхан өлкәсе) буйларында хәйран гына җәелдерәләр. IX–XII гасырларда Болгар дәүләтендә күп кенә (1200 дән артык) кирмәннәр, кальгалар, торулыклар һәм шәһәрләр барлыкка килә. Болгар, Суар, Биләр, Алабуга, Бряхимов (Ибраһим), Җүкәтау, Ашлы шәһәрләре, фәндә «Муром шәһәрчеге», «Хулаш шәһәрчеге», «Золотаревка шәһәрчеге», «Юлово шәһәрчеге» буларак һәм башка атамалар белән теркәлгән шәһәрләр мөһим хәрби-сәяси һәм мәдәни-икътисади үзәкләр буларак танылалар. Шул заманда гы борынгы рус һәм Көнбатыш Европа

шәһәрләре белән чагыштырганда болгар шәһәрләре үзләренең мәйданнары һәм халкы исәбе-күләмнәре буенча алардан зуррак булганнар. Мәсәлән, Биләр (рус елъязмаларындагы «Великий город = Бөек шәһәр») 800 гектардан артык мәйдан биләгән, анда 100 мең чамасы кеше яшәгән. Идел-Чулман Болгарстаны тормышында Дәште-Кыпчак һәм Төньяк Кавказ, Габбасыйлар хәлифәлеге һәм Харәзем, төньяк һәм көньяк рус кенәзлекләре, Византия, Балтыйк буе һәм Скандинавия, Һиндстан, Әфганстан һәм Кытай илләре һәм халыклары белән багланышлар әһәмиятле роль уйнаган [7; 8].

Дәүләттә ислам дине өстенлек итә, ул Идел-Урал төбәгенә IX гасырның икенче яртысында үтеп керә башлый, 922 елда Болгарстанның рәсми дәүләт дине дәрәҗәсенә ирешә. Шул елда Идел Болгарстанында Багдад хәлифәсе әл-Мокътәдирнең илчелеге булып китү исламның дәүләттәге урыны ныгуга һәм дөньяда дипломатик яссылыкта мөселман иле буларак танылуга зур йогынты ясый. X гасыр ахырыннан илнең төп халкы тулысынча диярлек мөселманлаша. X–XIII гасырларда Урта Идел буйлары һәм Урал буеның көнбатышы чикләрендә болгар, бәрәнҗәр, барсил (берсула), биләр, суар (суаз, савир), әсгал (искил) кабиләләреннән, бортас, мажар, кыпчак һәм угыз-бәҗәнәк кабиләләренең аерым төркемнәреннән бердәм телгә, рухи һәм матди мәдәниткә ия бердәм болгар халкы оеша, Болгарстан исә югары үсешкә ирешкән игенчелек, терлекчелек, шәһәрләр төзелеше, һөнәрчелек һәм сәүдә иленә әверелә, әлеге чынбарлык безгә заманында Көнчыгыш Европада үзенчәлекле Болгар цивилизациясе яшәвен икърарлау мөмкинлеген бирә [9; 10]. Дәүләттә сәнгатьнең һәм әдәбиятның, фәннең һәм монументаль мигъмариятнең күп кенә төрләре үсеш кичерүе шул хакта шаһитлек итә. Мәгарифнең күп тармаклы һәм төрле белем бирү дәрәҗәләрен үз эченә алган системасы хөкем сөргән шартларда Болгарстан халкы (ир-атлар һәм, мәсәлән, Туйбикә, Рабига хатын-кызлар мәдрәсәләре мисалында, хатын-кызлар) дин һәм дөньяви фәннәр нигезләрен өйрәнгән, үзләштергән, моның нәтиҗәсендә тарихта танылган бол-

гар илаһият галимнәре, философлар, язучылар, тарихчылар һәм географлар, башка фәннәр вәкилләре үсеп чыккан (бу очракта шагыйрь Кол Гали, тарихчы Йакуб бине Ногман, табиб Тажетдин бине Юныс әл-Болгари, шулай ук философлар һәм язучылар Сөләйман бине Дауд әс-Саксини әс-Сувари, Әбү-л Галә Хәмид әл-Болгари, Борһанетдин әл-Болгари, Газнәвиләр дәүләте солтаны Ямин әд-Дәүлә Мәхмүд Газнәвинең остазы һәм вәзире Хуҗа Әхмәд әл-Болгари исемнәрен күрсәтеп узу да җитә).

Шулай итеп, XIII гасырга кергәндә Идел-Чулман Болгарстаны чын мәгънәсендә бөтендөнья тарихының үзенә бертөрле һәм мөһим күренешенә әверелә. 1230 еллар уртасында «Бөек Венгрия»не эзләп табу нияте белән көнчыгыш тарафка ике тапкыр сәяхәт сәфәре кылган венгр монахы Юлиан: «Идел Болгарстаны — бай шәһәрләре булган бөек һәм куәтле дәүләт», — дип яза. Ләкин шул чорга кадәр берничә аерымланган бәклеккә таркалган Болгарстан 1236–1237 елларда Бату хан гаскәрләре тарафыннан яулану нәтиҗәсендә ил буларак яшәүдән туктый, XIII гасырның икенче яртысында аның территориясе тулысынча Җүчи Олысы (Алтын Урда) составына кертелә. Соңрак Идел Болгарстаны халкы урта гасырлардагы татар этносының гаять мөһим компонентларыннан берсен – илнең мәдәнияте татар тарихи-мәдәни мирасының әһәмиятле состав өлешен тәшкил итә.

Алтын Урда дәверендә Чыңгызый-Җүчиләрнең әлеге гаять зур империясендә төрки телле халыкларның сәяси, икътисади һәм этномәдәни туплануының һәм урта гасырлар татар халкының — хәзерге татар милләтенең элгәресе оешуының төп процесслары бара. Хәзерге вакытта фәндә Алтын Урдада 200 ләп шәһәр булуы мәгълүм, шуңа күрә бөтенлекле Алтын Урда цивилизациясе хакында сүз алып бару өчен тулы нигез бар [11]. Илнең иң эре шәһәрләре исәбендә Болгар (Алтын Урданың беренче башкаласы, хәзерге Татарстан), Сарай әл-Мәхрусә һәм Хаҗитархан (Әстерхан өлкәсе), Сарай әл-Җәдид һәм Бәлҗәмин (Волгоград өлкәсе), Мухша/Наровчат (Пенза өлкәсе), Үкәк (Саратов өлкәсе), Азак (Ростов өлкәсе), Маҗар (Ставрополь крае), Дәр-

бәнт (Дагстан), Кырык-Ир һәм Кырым/Солхат (Кырым), Ак Кирмән (Украина), Сарайчык һәм Сыганак (Казакъстан), Үргәнеч (Үзбәкстан), Искер/Себер (Төмән өлкәсе) һ.б. калалар танылган [12]. Урта Идел буендагы Болгар, Җүкәтау, Иске (Эчке) Казан, Казан, Кашан, Кирмәнчек һ.б. шәһәрләрдә Алтын Урданың Болгар олысының административ хакимият, һөнәрчелек, сәүдә, мәдәни һәм дини үзәкләре тупланган. Тарихи чыганаклар тәгаен рәвештә XV гасырның икенче утызъеллыгына кадәр, Казан ханлыгы оешканчы ук, Урта Идел буенда үзәге Казанда урнашкан дәүләти берләшмә булуын чагылдыралар. Мәсәлән, Казан елъязмачысы «Казан Урдасы»ның Бату хан улы Сартак тарафыннан XIII гасыр уртасында ук оештырылуын шаһитлек итә. XIV гасырда, Болгар, Җүкәтау һәм Кирмәнчек шәһәрләре белән берәттән, Казан нәкъ менә җирле «бәклекләр»нең берсенең сәяси үзәге сыйфатында искә алына. Бу исә, бердәм Алтын Урда кысаларында булса да, XIV гасырда Казанның Сарайдан суверенлыгы көчәя баруын ачык күрсәтә. Җүчи Олысының таркалуы Алтын Урда цивилизациясе традицияләрен дәвам иткән һәм бөтенлекле урта гасырлар конфедерациясен төзегән яңа дәүләтләр «йолдызлыгы» хасил булуга китергән... [13].

Хәзерге татар халкының килеп чыгышы һәм аның мәдәнияте оешуы турыдан-туры Алтын Урда дәвере белән бәйле. Татарлар — төрки телле бай тарихлы һәм мәдәниятле, XIX–XX гасырлар чигендә милләт буларак формалашкан халык, Россия Федерациясенең сан җәһәтендә икенче урынны биләүче, Татарстан Республикасының һәм Башкортстан Республикасының төп халкы. Татарлар Россия Федерациясенең күп кенә шәһәрләрендә һәм төбәкләрендә (Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә, Санкт-Петербургта һәм Ленинград өлкәсендә, Идел һәм Урал буйларында, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта) тупланып, шулай ук Казакъстанда һәм Үзәк Азиядә, Украинада, Төркиядә, Әзәрбайҗанда, Грузиядә, АКШта, Кытайда, Көнчыгыш Европа һәм Скандинавия илләрендә, Япониядә һәм Австралиядә сибелеп яшиләр. Исәпләүләр буенча, татарларның дөньяда гомуми саны — 7–10

млн чамасы кеше, Россиядә — 5 млн тирәсе, Татарстанда — 2 млн, Башкортстанда — 1 млн, чит илләрдә — 500 дән (Польша) 200 меңгә кадәр кеше (Казакъстан, Үзбәкстан; Әфганстандагы, Пакъстандагы һәм Ирандагы татарларның саны субъектив сәбәпләр аркасында исәпләнелмәде).

Беренче тапкыр «татарлар» атамасы анык һәм тәгаен рәвештә Шәркый Төркестанның борынгы төрки-монгол кабиләләрендә V–VI гасырларда — Жуҗан каһанлыгы таркалган чорда (сөннәрнең бер ыругы һәм жуҗан хөкемдарларының берсенең исеме буларак) һәм Төрки каһанлык оешкан заманда («утыз-татар» кабиләләр берлеге политонимы сыйфатында) теркәлгән. VII–XII гасырларда ул этнополитоним буларак Көнчыгыш һәм Үзәк Евразия территориясендә, XIII гасырда Сары диңгездән Дунайга кадәр җәелгән гаять зур Монгол империясе җирләрендә (ни сәбәпледер «татарлар» атамасы теркәлмәгән Чагатай Олысыннан гайре) киң кулланылган.

Хәзерге татарлар тарихы саклар, һуннар (сөннәр) һәм гуннар тарихын, Көнбатыш Төрки һәм Көнчыгыш Төрки, Авар, Уйгыр һәм Кимак каһанлыклары тарихын, Кара диңгез буендагы Бөек Болгар һәм Хәзәрстан тарихын, бәҗәнәкләр һәм кыпчаклар тарихын, Идел Болгарстаны һәм Үзәк Азиядәге XI–XII гасырлардагы татар дәүләтләре [14] тарихын үз эченә ала. XIII–XV гасырларда Алтын Урдада (Жүчи Олысында) «татарлар» атамасы (политоним, соционим, этноним), баштарак — хәрби-йомышлы катлауны, соңрак исә дәүләтнең шәһәр агломерацияләренең зур өлеше мөселманлашкан һәм төрки телләрнең кыпчак төркемендәге бердәм телдә аралашкан халкын аныклап, этник җәһәттә туплану-берләшү мәгънәсенә ия булган. Әлеге халык яңа әдәби («Идел буе төрки») тел формалаштырган, шул телдә фәнни һәм әдәби җәүһәрләр — Борһанетдин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар», 1310 ел), Әбүбәкер Каландарның «Каландарнамә» (1320–1340 еллар), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353 ел), Мәхмүд әс-Сараи әл-Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис» («Ожмахларның ачык юлы», 1358 ел), Хи-

сам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1369 ел), билгесез авторның «Кисекбаш», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1383 ел), Сәйф Сараинең «Китабе Гөлестан бит-төрки» һәм «Сөхәйл вә Гөлдерсен» (1391 ел) әсәрләре, Әхмәд Хуҗа әс-Сараинең, Мәүла Казый Мөхсиннең, Мәүләна Исхакның, Фәкыйһ Бәркәнең лирик шигырьләре һ. б. ижат ителгән. Алтын Урта дәверенең хәлиткеч тәэсирле тарихи вакыйгалары «Идегәй» дастанында чагылыш тапкан [15].

Җүчи Олысында ислам диненең, язуның һәм норматив әдәби телнең киң таралыш алуы, интенсив шәһәрләшү ил халкының зур өлешенең актив рәвештә бер үзәккә тартылуының, аның ыруг-кабилә кысаларыннан арынуының һәм шуның нәтиҗәсе — татар этносәяси бердәйлегенең формалашуының һәм ныгуының мөһим элементы буларак бәяләнә. Алтын Урда таркалганнан соң, яңа татар дәүләтләре — Әстерхан, Казан, Касыйм, Кырым, Төмән/Себер ханлыклары барлыкка килә, соңрак алар территориясендә бердәм «татарлар» үзатамасы тәмам ныгып урнаша…

Шулай итеп, хәзерге Татарстан һәм татар халкының үткәненең яралгы башлангычы һәм тарихы күп кенә йөзләрчә елларны колачлый. Татар милләтенең килеп чыгышы, аның мәдәниятенең барлыкка килүе һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге, сәяси хакимияте оешу процессы (политогенез) катлаулы булып, үзләренең һәртөрле «тарихкача» һәм тарихи этапларын узганнар, биредә без фәкать Идел-Чулман Болгарстаны һәм Алтын Урда чорларын кыскача күздән кичердек...

Идел-Чулман Болгарстаны һәм Алтын Урда тарихын һәм мәдәниятен фәнни яссылыкта популярлаштыру актуальлеге, рус һәм татар телләрендә «Идел Болгарстаны» һәм «Алтын Урда» мультимедиа академик энциклопедияләрен булдыру зарурлыгы хакында безгә 2024 елда «Мәдәни җомга» газетасы, 2025 елда «Гасырлар авазы» журналы сәхифәләрендә язып чыгарга, IV Халыкара «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, практика» («Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика») семинарында,

VI Халыкара Евразия далалары археологиясе конгрессында, Халыкара «Хәзерге инновацион таләпләр контекстында төбәк энциклопедистикасы» («Региональная энциклопедистика в контексте современных инновационных вызовов») фәнни форумында, Халыкара «Казакъстан һәм Татарстан: үткәндәге һәм хәзерге гуманитар һәм мәдәни багланышлар» («Казахстан и Татарстан: гуманитарные и культурные связи в прошлом и настоящем») фәнни семинарында чыгышлар ясарга туры килгән иде [16; 17].

Нәтиҗәдә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе җитәкчелеге тарафыннан әлеге мөһим академик башлангычларның актуальлеге һәм аларны гамәлгә ашыруның максатчанлыгы хакында соңгы нәтиҗә чыгарылды. Әлеге темалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2026 елның 26 гыйнварында раслаган Татарстан Республикасының «Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» төбәк программасында лаеклы урын алдылар (программаның гамәлгә ашырылу чоры: 2026–2034 еллар).

Фаразыбызча, «Идел Болгарстаны» һәм «Алтын Урда» энциклопедияләрендә рус һәм татар телләрендә Идел Болгарстаны һәм Алтын Урданың яралгы тарихлары, әлеге дәүләтләрнең тарихы, географиясе, аларның тарихи-мәдәни һәм рухи мирасы, хәзерге чорда шул өлкәләрдә гыйльми тикшеренүләр алып барган затлар хакында чагылдырылган бай мәгълүматлы материаллар урын алырга тиеш.

Һәртөрле энциклопедиянең концепциясен һәм сүзлекчәсен эшләү аны булдыру юнәлешендә фарыз тәүге гамәл икәнлеге табигый. 2024 ел ахырыннан әлеге юллар авторы һәм ТР Фәннәр академиясе Археология институты җитәкчесе Айрат Ситдыйков тарафыннан киң колачлы эш башкарылды, аның нәтиҗәсендә концепция эшләнде һәм телгә алынган энциклопедияләрнең беренчел сүзлекчәләре әзерләнде. Сүзлекчәләр төзү эше хәзер дә дәвам итә. Әлбәттә, киләчәктә «Идел Болгарстаны» һәм «Алтын Урда» энциклопедияләре, һичшиксез, фәнни өйрәнү һәм бәяләү, тәнкыйди күзлектән уздыру, камилләштерү өчен киң даирә фән-

ни җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителәчәк. Сүзлекчәләр расланганнан соң, без – иҗат коллективы туплау һәм энциклопедия мәкаләләре язу эшенә керешәчәкбез.

Әдәбият исемлеге

1. Халиков А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М.: Наука, 1969. 396 с.
2. Фәхретдинов Р.Г. Татар тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 104 б.
3. Смирнов А.П. Волжские булгары. М.: ГИМ, 1951. 277 с.
4. Халиков А.Х. Беренче дәүләт: Болгар иле. Казан: Тат. кит. нәшр., 1991. 216 б.
5. Zimonyi I. The Origins of the Volga Bulghars // Studia Uralo-Altaica. Vol. XXXII. Szeged: Universitas Szegediensis de Attila József Nominata, 1990. 211 p.
6. Белов С.Г., Хамидуллин Б.Л. Волжские булгары. Путь к исламу. Казань: ИТЭР АН РТ, 2022. 136 с.
7. Археология Волго-Уралья: В 7 т. Т. 5. Средние века (VIII — начало XIII вв.). Волжская Болгария. Финно-угорский мир. Кочевники Восточной Европы. Казань: Изд-во АН РТ, 2022. 888 с.
8. Хуҗин Ф.Ш. Болгар илендә ислам һәм элгәреге шәһәрләр // Фәнни Татарстан. 2022. №2. 103–114 б.
9. Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 112 с.
10. Bulgarica. Время и пространство Болгарской цивилизации: атлас. М., Казань: Феория, 2012. 471 с.
11. Хәмидуллин Б. Алтын Урда цивилизациясе һәм аның мирасы // Казан утлары. 2019. №8. 173–178 б.
12. Зиливинская Э.Д., Васильев Д.В. Города Золотой Орды // Золотая Орда в мировой истории. Казань: ИИ АН РТ, 2016. С. 633–664.
13. Мухамедьяров Ш.Ф. Содружество постзолотоордынских татарских исламских государств // Очерки истории исламской

цивилизации: В 2 т. М.: Российская политическая энциклопедия, 2008. Т. 2. С. 119–122.

14. Кляшторный С.Г. Татарларның Үзәк Азиядәге дәүләтләре (монголларга хәтле чор) // Казан утлары. 2002. №9. 173–177 б.

15. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. I том. Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Тат. кит. нәшр., 2014. 415 б.

16. Хәмидуллин Б.Л. Татар һәм рус телләрендә «Идел буе Болгар дәүләте» һәм «Алтын Урда» энциклопедияләрен булдыру актуальлеге турында // Региональная энциклопедистика в контексте современных инновационных вызовов. Казань: Изд-во АН РТ, 2024. 456–461 б.

17. Khamidullin B.L. On the concept of encyclopedias «Volga Bulgaria» and «Golden Horde» // Археология Евразийских степей. 2025. №2. 367–369 p.